# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2024 елның 15 ноябре, № _4_

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**Карар:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизация, контракт төзеп хэрби операциягә киткән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз)сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
1) Дружба торак пунктында традицион җирләү урыннарын (агачларны һәм куакларны кисү, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, махсус техниканы арендалау) төзекләндерү;

2) Дружба торак пунктында урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы карап тору (шартнамә буенча лампа, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3. Әлеге карарны Ләке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы _____________ Ю.Г.Антонов